| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУРАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 февраль, 2024 Мөрәле ав. № 2

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Зур Колангы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 нче карарына үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Зур Колангы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыены әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 30 сентябрендәге 23 номерлы карары нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2024 елның 18 мартында 14 сәгатькә Колангы авылы, Бакча урамы адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Зур Колангы торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 нче карарына үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«Сез «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Зур Колангы торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 нче карарына җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәртергә һәм 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә ризамы?

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү? »

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннәтуллин